Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№27 (40)

11 октябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

3 октябрьдән алып 6сына кадәр Россия хезмәттәшлеге ярдәмендә оешытырылган «Россия һәм Германиянең очрашу елы» кысаларында **БЕРЛИНДА III ХАЛЫКАРА СТУДЕНТЛАР ФОРУМЫ УЗДЫРЫЛДЫ**. Чара Берлин университетлары: Гумбольдт ис. университет, техник университет, сәнгать университеты һәм, шулай ук, Берлиндагы Россиянең фән һәм мәдәният йорты базасында үткәрелде. Форумда Россия һәм Германиянең әйдәп барган уку йортларының 60тан артык җитәкчеләре, студентлары, аспирантлары, укытучылары катнашты. Безнең Казан федераль университетыннан да өч студентыбыз чарага барып кайтты.

• • • •

8 октябрь көнне **КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ӨЛКӘН БУЫННЫ ХӨРМӘТЛӘҮ ТАНТАНАСЫ БУЛЫП УЗДЫ**. Өлкәннәр ун көнлегенә (Россияда традицион рәвештә 1-10 октябрьдә үткәрелә) Җәмәгать туклану комбинатының зур залында бәйрәм оештырылган иде. Университетыбызның ректоры Илшат Гафуров килгән кунакларны өлкәннәр көне белән тәбрикләде. КФУ студентлары да, өлкәннәргә бүләк рәвешеннән, иң яхшы чыгышларыннан гына торган бәйрәм концерты оештырганнар иде.

• • • •

8 октябрь көнне ректорат утырышы залында **КФУ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ҺӘМ СУАН СУНАНДХ РАДЖАБХАТ (ТАИЛАНД) УНИВЕРСИТЕТЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ БЕЛӘН ОЧРАШУ БУЛЫП УЗДЫ**. Делегация составында Суан Сунандх Раджабхат университеты президенты Чуангчоте Бхунтувеч, университет аппараты җитәкчесе Корн Даббаранси, университетның халыкара колледж директоры Кронгтонг Хаирири бар иде. Очрашу нәтиҗәсендә ике университет арасында Үзара килешү турындагы меморандумга кул куелды.

• • • •

8 октябрь көнне КФУда һәр ел саен үткәрелә торган **«БЕРЕНЧЕ КУРСЛЫЛАР КӨНЕ» ФЕСТИВАЛЕ АЧЫЛДЫ**. Чара 24 октябрьгә кадәр уздырылачак. Быел факультетара бәйге үзенең киң колачлы булуы белән аерылып тора: фестивальдә төрле институт һәм факультетлардан барлыгы унтугыз команда катнашыр дип көтелә.

• • • •

Бүген **«РОССИЯ БЕЛӘН КЫТАЙ: ТАРИХ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН V ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ БАШЛАНАЧАК**. Чара Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты бинасының 5 катта урнашкан актлар залында узачак. Ул ике көн дәвам итәр дип көтелә.

• • • •

**11 ОКТЯБРЬ КӨННЕ КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНДА «ХӘЗЕРГЕ ЗАМАНДА ХАЛЫКАРА ХОКУК ТӘРТИБЕ ТОРЫШЫ ҺӘМ РОССИЯНЕҢ АНЫҢ ҮСЕШЕНДӘГЕ РОЛЕ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯНЕҢ ТАНТАНАЛЫ АЧЫЛЫШЫ БУЛАЧАК**. Чара профессор Давид Исаак улы Фельдманның тууына 90 ел булу уңаеннан оештырылган. Конференцияне оештыру өчен Казан федераль университеты һәм Россия халыкара хокук ассоциациясе җаваплы. Чара, шулай ук, ике көн буе барачак. Соңыннан катнашучылар өчен зур мәдәни программа – шәһәрнең данлыклы урыннары буенча экскурсия да каралган.

• • • •

Бүген, шулай ук, Урта Идел буе аграр тарихчыларның **«РОССИЯНЕҢ АГРАР СЕКТОРЫНДА ХУҖАЛЫКЛАРЫН АЛЫП БАРА ТОРГАН СУБЪЕКТЛАР: ТАРИХЫ, ИКЪТИСАДЫ, ХОКУКЫ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН IV БӨТЕНРОССИЯ (XII ХАЛЫКАРА) КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮЗЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Чарада катнашучылар биш секциягә бүленеп чыгыш ясаячаклар. Конференция 12 октябрьга кадәр дәвам итәчәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

# Күрегез - беренче курслар!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Ә сез университетка килеп кергән беренче көннәрегезне хәтерлисезме? Әллә яңа гына уку йорты бусагасын атлап кердегезме? Студентлык дигән күңелле чорның кабатламас атмосферасына күмелергә теләсәгез, университетта ел саен уздырыла торган «Беренче курслар көне» фестиваленә рәхим итегез!

Быел, үткән еллардан аермалы буларак, чарада катнашучы командалар саны артты - биредә төрле институт һәм факультетлардан 19 команда көч сынаша.

Фестивальне 8 октябрь көнне «УНИКС» концертлар залы сәхнәсендә юридик факультет, филология һәм сәнгать институты, физика институты «йолдызлары» башлап җибәрде. Аерым факультет яки институтның чыгышларын билгеле бер вакыйгага, тарихка, темага бәйләү үзенә күрә бер күркәм традиция. Әйтик, филология һәм сәнгать институты вәкилләре студент тормышын зур диңгездә сәяхәт иткән кораб белән чагыштырып, үзләренең барлык чыгышларын да шундый бер җепкә тезгәннәр. Программаларын алар «Йөз!» («Плыви») җырыннан башлап җибәреп, курсташларына шушы образ аша зур юлда уңышлар теләде. Юридик факультет вәкилләре исә үз чыгышларын студентлар тормышында була торган көндәлек вакыйга – дусларның сөйләшеп торуы, фәлсәфә коруга бәйләгән иде.

Чыгышларга килгәндә, университетыбыз студентлары тарафыннан үткәрелә торган концертларга елдан-ел сакланып килә торган сыйфат – тәфсилләп әзерләнгән хореография, шактый тәэсирле вокал, беренче курс студентларында гына түгел, өлкән курс студентларының, укытучыларның күңелләрендә дәрт, ниндидер якты хис, яңа үрләргә омтылырга теләк уята торган шигырьләр, җыр текстлары, гадәттәгечә, чараның ныклы нигезе булып торды.

Безнең студентлар бер урында гына таптанып тормый, бөтен нәрсәгә һәрвакыт ниндидер яңалык кертергә тырыша. Фестивальдә дә шулай – талант ияләре тамашачыны гаҗәпләндерү, сокландыру өчен яңадан-яңа алымнар уйлап тапкан. Әйтик, юридик факультет чыгышлары арасында берсе аеруча игътибарымны җәлеп итте. Бер кыз бик тә хисле, моңлы җыр башкара, ә шул вакытта сәхнәнең икенче читендә бер егет зур ак кәгазь битендә романтик рухтагы рәсем төшерә. Хокук белгечләренең тагын бер үзенчәлекле номеры – өч төрле шәрык биюен бер чыгышта җыеп күрсәтүнәкъ яшьләргә хас булган динамиканы ачык чагылдырды.

Шулай да фестивальдә катнашучы студентлар сәнгатьнең яңа агымнарына гына игътибар биреп чикләнмәгән. Чыгышлар арасында элек-электән килгән традицион номерлар да бар иде. Татар халык биюе дисеңме, рус фольклорына караган, заманча рухта эшкәртелгән җырлар дисеңме, блюз юнәлешенә караган музыка дисеңме!..

Гомумән, фестивальнең беренче көне барлык тамашачыларда бары тик уңай тәэсирләр калдырды дип уйлыйм. Күтәренке рухтагы әлеге чараны караган һәрбер студент һәм укытучыларга уку елы башында яңа көч, энтузиазм һәм яхшы кәеф бүләк итә!

## • Чара

# Мәгарифтә дә, фәндә дә IT кирәк!

**Рифат СӘЛАХ**

Хәзер һәр яңа туган бала беренче эш итеп кулына iPad ала икән. КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Данис Нургалиев хәзерге заманда мәгълүмат чараларын киң кулланмыйча мөмкин түгел дип саный. Бу фикерен ул 8 октябрь көнне «Мәгарифтә һәм фәндә мәгълүмат технологияләрен куллану» (ИТОН) дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференциянең ачылышында җиткерде. Әлеге чара 12 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

**Ахыры 2нче биттә.**



• Чара

# Мәгарифтә дә, фәндә дә IT кирәк!



■ Сулдан икенче конференцияне оештыру комитеты рәисе С.Григорьев

**Башы 1нче биттә.**

*Тантаналы ачылышта, шулай ук, КФУның инновацион эшчәнлек буенча проректоры Наил Кашапов, Мәскәү дәүләт педагогика университеты профессоры, конференциянең оештыру комитеты рәисе Сергей Григорьев, оештыру комитеты рәисе урынбасары Юрий Игнатьев, Н.Лобачевский исемендәге КФУның Математика һәм механика институты директоры Владимир Чугунов, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры Рөстәм Латыйпов чыгыш ясады.*

*Сергей Григорьевны конференциядә катнашучылар торып басып алкышлады. Аңа шушы көннәрдә алтмыш яшь тулган икән. Заманында үзе дә Казанда белем алган профессор, мондый конференциянең КФУда үткәрелүенең сәбәбен университетыбызның бу өлкәдә зур үсеш кичерүе белән аңлатты. «Бездәге кебек IT-мәктәп дөньяда да сирәк», – диде ул.*

*Владимир Чугунов әйтүенчә, бу вакыйга Н.И.Лобачевскийның 200 еллыгы якынлашып килгән көннәрдә үткәрелә. Бу чарада Россиянең башка төбәкләреннән дә, чит илләрдән дә килгән галимнәр катнаша. Алар мәгарифнең бөтен өлкәләрендә дә мәгълүмати технологияләрне куллану проблемалары турында фикер алышачак. Уку процессыннан кала, дистанцион белем алуны оештыру, мәгълүматлар базасы, электрон китапханәләр төзү кебек мәсьәләләр дә каралачак. Конференция кысаларында мәгълүмати технологияләр методын, математик модельләштерү һәм компьютер математикасы ысуллары белән фундаменталь һәм кулланма фәнни тикшеренүләр үткәрү буенча Икенче бөтенроссия фәнни семинары да үткәреләчәк.*

*Конференциядә өр-яңа IT-технологияләр презентациясе, заманча компьютер җиһазлары, махсус программалар һәм фәнни әдәбиятны сату-алу күргәзмәсе булачак. Шулай ук, чара барышында мәгълүмати технологияләр буенча мастер-класслар алырга да мөмкин.*

Алия Галимуллина фотолары



• Чит җирләрдә

# Баку - үзебезнеке!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Узган атна ахырында Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиев яисә Рәдиф Рифкатович Җамалетдиновны бөтен университет буенча эзләп йөрергә туры килмәдеме? Эзләгән булсагыз да таба алмадыгыз, шулай бит? Гаҗәп тә түгел, чөнки аларны бу вакытта Бакуда кунак иттеләр.



4-5 октябрь көннәрендә Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов белән академик Мирфатыйх Зәкиев ел саен уздырыла торган Баку халыкара гуманитар форумында катнаштылар. Анда дөнья галимнәренең иң дәрәҗәлеләре генә җыела.

Рәдиф Җамалетдинов татар лингвокультурологиясе өлкәсендәге тикшеренүләр белән уртаклашып кайтты. Моңа өстәп ул, Баку славян университеты ректоры Камал Абдуллаев белән КФУның филология һәм сәнгать институты исеменнән ике арада хезмәттәшлек итү турындагы килешүне имзалаган.

Нинди максатлар белән барганнары турында, без М.З.Зәкиев белән сөйләштек: «Азәрбайҗан җитәкчеләре «Баку халыкара гуманитар форумы» дигән бик зур чара оештырганнар. Безне анда бик яхшы каршы алдылар, кунак иттеләр, бик зур рәхмәт аларга!

Әлеге форум үзенең эшчәнлеген күптән түгел генә, 2010 елны, башлап җибәрә һәм быел икенче мәртәбә җыела. Аның төп максаты: бөтен дөньяга Азәрбайҗан республикасының үсеш темпларын, хәзерге чорын һәм киләчәген күрсәтү, Азәрбайҗанны халыкара күләмдә яктырту. Чарада катнашырга дип җитмешләп илдән төрле өлкәдә эшләүче шәхесләр чакырылган: халыкара күләмдә танылган галимнәр, шуларның унбере Нобель премиясенә лаек булган. Төрле дәрәҗәдәге дәүләт эшлеклеләре бар иде.

Беренче көнне, чараны ачып җибәргәндә Азәрбайҗан президенты Илһам Алиев үзенең чыгышында: «Хәзерге чорда нефть чыгарып юллар да булдырылган, зур төзелешләр дә алып барыла һәм безнең бүгенге көндә төп бурычыбыз: яшьләрне тәрбияләү, яшь буынны киләчәк тормышларын төзерлек итеп әзерләү», - диде. Юнеско вәкилләре дөньякүләм мәдәният багланышларын тәэмин итү турында мәгълүмат белән таныштырып үтте. Россия президенты В.В.Путинның мөрәҗәгате укылды, төрле илләрнең элеккеге президентлары, тәҗрибәле кешеләр чыгыш ясады. Азәрбайҗан турында яңа фильм күрсәтелде.

Без Казаннан өч кеше бардык: мин, Рәдиф Җамалетдинов һәм психолог Рамил Гарифуллин. Икенче көнне уздырылган түгәрәк өстәлдә катнаштык. Чыгышларыбыз «Бүгенге заман массакүләм мәгълүмат чаралары һәм аларның кулланылышы» дигән темага карады. Элек төрки халыклар турында бик яшь халык, һинд-европалылар яшәгән җиргә килеп урнашканнар дигән фикер яшәгән. Бу исә, дөреслеккә туры килми һәм яңача «хәбәр итү» дигәндә, андый фикерләргә каршы килеп, тарихи дөреслеккә туры килгән вакыйгалар белән раслау күзаллана. Шулай ук, КФУда яшьләрне тәрбияләүдә нинди юнәлешләргә игътибар бирүебез турында да сөйләдек.

Гомумән, азәрбайҗанлыларның татар мәдәниятенә карата мөнәсәбәтләре бик яхшы. Бәйләнешләрне ныгытыр өчен үз өлешемне керттем: 1972 елдан бирле аларга еш кына татар тарихы, мәдәнияте турында барып лекцияләр укып кайтам. Ошаталар ахрысы, чакырып кына торалар. Шулар белән беррәттән, Татарстандагы фән торышы, фәнни кадрлар, студентларны кабул итү, аларны эшкә урнаштыру турында мәгълүмат бирәбез. Алар Татарстанны яхшы белә, һәрдаим кызыксынып торалар.

Вакытыбыз бик тыгыз булу сәбәпле, оештырылган экскурсияләргә бара алмадык, шулай да, Баку-Славян университетында кунак булып алдык. Кызганыч, бу юлы студентлар белән очрашырга насыйп булмады. Студентлар яшь, алдынгы карашлы, энергияләре ташып торучан халык. Үземә кирәкле рухи көчне алардан да алам,» – дип елмаеп куйды Мирфатыйх ага.

Университетыбыз галимнәрен кая гына барсалар да ачык йөз белән каршы алалар. Белем йортыбызның югары дәрәҗәле булуына ишарә түгелмени бу!

• Бездә кунак бар

# Уңыш нигезендә – тырышлык!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

8 октябрь көнне Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлегендә «Тылсымлы куллар» балалар журналының редакторы Ландыш Хәмит кызы Фазуллина белән очрашу булып үтте.

Татар әдәбияты тарихы кафедрасы доценты Луиза Фирдүс кызы Җамалиева оештырган бу түгәрәк өстәлнең темасы да бик кызык – «Бүгенге заман шартларында балалар журналы бастыруның кайбер үзенчәлекләре». Очрашу гади генә булмады, чөнки Ландыш Фазуллина студентларга уңышка ирешүнең кайбер серләре белән уртаклашты. Уңышка ирешим дисәң, хәзерге заман шартларында күп көч куярга кирәк. Монысын гына беләбез... Тырышлык, ихтыяр кирәк – ә андый көчне каян алырга соң?..

Белүегезчә, Ландыш Фазуллина узган елны үткәрелгән Яшьләр форумында «Киләчәккә старт!» номинациясендә, «Тылсымлы куллар» балалар журналын тәкъдим итеп, беренче урынны алган иде. Шул исәптән, башка бик күп конкурсларда да аның бу проекты җиңүгә ирешә. Ландыш апаны «Тылсымлы куллар» журналын бастырып чыгарырга кибетләрдә кече яшьтәге балалар өчен яраклы татарча басмаларның очрамавы этәргән. Чыннан да, кая гына карасаң да, урыс телендәге басмаларны күрергә була, әмма татар телендәгеләре – бигрәк тә сабыйлар өчен сирәк. Журнал бастыру һәм барысын да «нольдән» башлар өчен никадәр тырышлык киткәнен үзе бу дәрьяда йөзмәгән кешегә аңлавы кыенрактыр, мөгаен.

«Беренче чиратта, эчке теләк булырга тиеш, күңелеңдә ниндидер максатка ирешү омтылышы уянган очракта гына үзеңдә ниндидер көч табып, зур эшкә тотынырга була. Әлбәттә, башлап җибәргәндә кыенлыклары күп иде. Үз эшеңне ачу өчен матди як та ныклы булырга тиеш. Башымда бертуктаусыз уңышка ирешәчәкмен дигән уй йөрүе – бүгенге көндәге уңышларымның төп сәбәпчеседер, мөгаен», – дип, очрашу башлаганчы ук безне бик җитди уйларга чумдырды Ландыш апа. Уйлап карасаң, һәрберебезнең рәхәт тормышта яшисе, яраткан эше белән шөгыльләнәсе килә, тик үзендә көч таба алучылар сирәк. Тәвәккәллек дигән сыйфат җитенкерәми. Бу бәлки куркудан да киләдер. Ландыш ханымның уңышка ирешүенең тагын бер сере: һәр эшләнәсе этапны исәпләп, планлаштырып бару. Башта бер көнгә эшләнәсе эшләрне язып куясың, аннан соң бер атнага, айга, елга һәм хәтта биш елга да мондый планисемлекне төзеп куярга була. Төзеп кенә түгел, ә язып кую шарт. Ландыш апаның максатчанлыгы күзләрендәге нурдан ук күренеп тора, үз эшен шулкадәр яратып һәм теләп башкаруы, миңа калса, шундый матур балалар журналының туында төп сәбәпчедер.

Очрашу ахырында ул студентларга «Тылсымлы куллар»ны бүләк итте. Дөрестән дә, бик мавыктыргыч басма. Бәләкәй сабыйга гына түгел, ә миңа да бик кызыклы, үзенчәлекле булып тоелды. Өйгә кайткач әле могҗизалы рәсем ясап карарга да вакыт таптым. Ә Ландыш апага милләтебезне, динебезне, телебезне саклардай кыз һәм улларны тәрбияләп үстерергә «Тылсымлы куллар»ы белән үз өлешен кертүе өчен рәхмәтебезне белдерәбез. Киләчәктә исә, тагын да зуррак уңышларга ирешсен һәм, иң мөһиме, тормышка булган оптимистик карашы, ягымлы елмаюы һәрчак укучыларын җылытып, рухландырып торсын!



● Кечкенә галимнәр

Рәшидә Габдрахманова:

# «Тагын сайлау мөмкинлеге булса, укытучы дияр идем!»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Рубрикабызның бүгенге кунагы- педагогика фәннәре кандидаты, КФУ ның педагогика һәм психология институтының педагогика кафедрасы доценты Габрахманова Рәшидә Габделбакиевна. Әнвәр Хуҗиәхмәтов җитәкчелегендә диссертация яклаган Рәшидә ханым бик күп еллар студентларны педагогика фәне серләренә төшендерә. Аның яшьлек, балачак еллары хатирәләре белән сезне дә таныштырабыз.

«М«Мәктәптә укыганда һәр фәнне ныклап өйрәнергә тырыштым. Гомумән, укырга теләп йөрдем, яратып белем алдым. Яхшы укыгач, гел бишлеләр генә аласы килә башлый, дүртле алгач күңел төшә. Бервакыт шулай укытучыбыз рус теленнән диктант яздырыр алдыннан: “Диктантыгыз ничәле булса, чиреккә дә шул билге чыгар”,-диде. Тырышыптырышып һәр өтерен, һәр сүзен җентекләп тикшереп яздым диктантның. Бишле булды. Ә чиреккә нигәдер дүртле чыгарып куйды. Бу минем күңелемә бик тиде, чөнки укытучыбыз үз сүзендә тормады. Шул вакыйганы истә тотып, укучыларыма, студентларыма карата һәрчак гадел булырга тырышам.

Мәктәпне тәмамлагач кем булырга дип уйлап торырга да вакыт булмады. Гаиләбездә бөтенесе педагоглар. Мин дә укытучы һөнәрен үзләштердем. Институтны тәмамлап, беренче елны мәктәптә эшли башлагач, бик кыен булды. Сәбәбе дә гади: мәктәпләрдә татарча бер авыз сүз әйтергә ярамый. Балалар аңламый, ә аларга: «Балакаем, торып бас», – димим, гәрчә үзем татар телен белсәм дә. Кануны шундый иде.



Шактый гына мәктәптә укытучы булып эшләдем. Шуңа бәйле тагын бер кызыклы хәл исемдә калган. Мин җәйге лагерь җитәкчесенең урынбасары идем. Җитәкчебез бөтен эшләрен миңа калдырып, һәрчак командировкаларга, йә булмаса башка җиргә китә. Балалар белән «Аҗаган» уенын үткәрергә булдык. Кайда диярсез? Урманда! Әйдаманнар арасында бер кыз, урманны биш бармагым кебек беләм, әйдәгез үзем алып барам ди. Шулай итеп, физкультура укытучысы, мин һәм 20 яшьлек әйдаман кыз – өчәү урманга биремнәр төзергә киттек. Йөри торгач адашканыбызны аңладык, әйләнәбез дә һаман бер җиргә чыгабыз, әйләнәбез дә – тагын шунда. Әйдаман кыз бездән уңайсызланып, ни дияргә дә белмичә юлны табарга тырыша, ләкин юк – без, җаваплы кешеләр, үзебез дә урман уртасында адашып калдык. Бер өч-дүрт сәгать ары-бире йөргәннән соң, машина тавышы ишетеп, юлга таба атладык. Бу вакыйгадан соң, «Аҗаган»ны урманда үткәрү турында уйлау да мөмкин түгел иде. Уенны кырда үткәрдек. Бу хәл минем өчен тагын бер сабак булды. Балалар белән эшләр алдыннан, оештыру мәсьәләсен энәсеннән җебенә кадәр карап бетерергә кирәк дигән фикер аңыма сеңеп калган.

Югары уку йортында эшли башлагач, аптыраштa калдырган тагын бер очрак булды: диссертация эшемне язып бетереп, фәнни җитәкчем, Әнвәр Нуриәхмәт улына тикшертергә бирүем. Ул бер кат карап чыкты да, хаталарын төзәтеп, шактый калын гына диссертацияне миңа тоттырды. Мин инде өйгә кайткач, җентекләп, һәр юлын, хатасын карап, тикшереп чыктым. Төгәлсезлекләр калмаганлыгына инангач, янәдән тикшертергә алып килдем. Әнвәр абый: «Игътибар белән карадыгызмы?» – дип сорый. Күземне дә йоммыйча: «Әйе», – дидем. Ул ике дә уйламыйча калын битләрнең урта бер җирен ачты да: «Ә бу нәрсә, ник карап бетермәдегез?!» – дип мине гаҗәпләндерде. Дөрестән дә, кайсыдыр өлешен күрмәгәнмен, ә ул бик тиз генә ниндидер гайре табигый көч белән хаталы урынын төртеп күрсәтте... Аллага шөкер, бүгенгә кадәр университетыбызда студентларга белем бирәм. Яңадан берәр профессияне сайларга мөмкин булса, уйлап та тормастан – укытучы дияр идем!..»

● Иң шәп төркем

# Күңелләр бердәм булганда күңелле!

**Рания САФИНА, Гөлфия ШӘВӘЛИЕВА,**
татар филологиясе бүлеге студентлары

Таныш йөзләр, таныш күзләр?.. Әйе, әйе! Бу «Иң яхшы академик төркем» конкурсы лауреатлары, яшьнәп торган яшьләр – 05.07-1002 төркеме студентлары!



Әле күптән түгел уку йортыбызның ишекләрен киң ачып, тәүге адымнарны атлап кергән идек. Вакыт сизелми дә үтә икән: без инде өченче курска җиткәнбез. Гомернең шулай үтүенең сере нидә дисезме? 05.07-1002ләр җавабын озак уйлап тормас!

Студент тормышының һәр мизгеле үзенә бер төрле. Безнең төркемнең девизы: «Иң мөһиме күңелләрнең бергә булуы!» Төркемебез, гомумән, бик актив һәм шаян. Һәр мизгелне дә матур, истә калдырырлык итеп үткәрергә тырышабыз. Укуда гына түгел, ял иткәндә дә бердәм без.

Иң яхшы академик төркем бәйгесендә җиңү яулап, төркемебезнең бүтәннәрдән аерылып торганлыгын тагын бер кат дәлилләдек. Бу уңайдан, көзнең кояшлы матур көннәренең берсендә Болгарга барып кайттык. Күтәренке кәеф белән җырлыйҗырлый баргач, юлның озынлыгы сизелмәде дә. Колач җәеп безне Идел каршы алды һәм үзенә гашыйк итеп тә куйды. Ә Болгар җиренең гүзәллеген сөйләп кенә аңлатып бетерерлек түгел.

Күңелгә иң хуш килгәне – Ак мәчет. Әлеге зур мәһабәт бина бөтенебезне таң калдырды. Мәчеткә керү белән тәнгә җылылык йөгерде, күңелгә тынычлык килде. Әйтерсең, мәчет аклыгыннан бөтен җаныбыз да сафланып калды. Ул бинага карап кына да, озак уйланып торырга була. Ак мәчет эчендә үзебезне әкият дөньясына эләккәндәй хис иттек.

Ул көнне елмаясы, шатланасы, җырлыйсы гына килеп торды. Гүяки безнең күңелгә дә кояш керде. Аллага шөкер, көне дә искиткеч җылы иде. Әлбәттә, мондый сәяхәтләр әле тагын да булыр. Алда әле күп хыяллар, озын юллар: якын киләчәктә Санкт-Петербургка барырга җыенабыз, Алла бирсә. Иң мөһиме, кая бару түгел, ә күңелләрнең бергә булуы!

● Ярдәм итик

# Син яшәргә тиеш, Фазыл!

**Әлмирә ӘГЪЗАМОВА,**
фундаменталь медицина һәм биология институты

Әй бу язмыш дигәннәре! Яшисең, эшлисең, укыйсың, якты киләчәккә өметләр баглыйсың... һәм кинәт кенә боларның барысы да бер мизгелдә туктап кала. Барлык хыяллар челпәрәмә килә, акланмаган өметләр буш куык кебек күккә оча да китә. Бер мизгел эчендә барлык тормышыңның асты өскә килә. Әйе, бик еш була мондый хәлләр... Килешмичә дә булмый... Тик... Боларның барсы да 20 яшьлек япь-яшь, зур дөньяга әле яңа гына аяк баскан, яшәүгә, җиһанга үлеп гашыйк булган егеткә бәйле булуын күңел кабул итә алмый, ышанасы килми! Күз яшьләренә буыла-буыла «нинди гаделсез дөнья соң бу!» дип Җир шарын ярып кычкырасы килә дә... Алай гына ярдәм итеп булмый... Ләкин өмет уты сүнмәгән әле.

Фазыл Фәрдиевка быелның җәендә коточкыч диагноз куела – ашказаны асты бизендә яман шеш авыруы. Ул иң соңгы стадияләрнең берсендә икән инде. Коточкыч чиргә Фазыл әле дә бирешмичә яши! Туганнары сүзенә караганда, Фазылның кинәт кенә 1 августтан башлап бик нык эче авырта башлый. Табибларга мөрәҗәгать иткәч, алар егетне бер атна буе гастрит авыруыннан дәвалый. Тик бу аларның ялгышы була... Кан анализы Фазылда рак күзәнәкләре барлыгын күрсәткәч кенә, аңа куркыныч диагноз куела.

Кечкенәдән үк актив, шук, һәрвакыт елмаеп торучы егетне бу авыру аяктан егар дип кем уйлаган? Фазыл яшьтән үк тырыш, акыллы, эшчән, музыка яратучы, аралашучан булып үсә. Бер бәйрәм дә, кичә дә Фазылсыз үтми. Әти-әнисе аны мәктәпкә иртә бирә, чөнки үз яшьтәшләреннән күбрәк белә торган, кызыксынa торган малай була ул. «Укытучылар белән бертигез дәрәҗәдә сөйләшә, бездән күбрәк белә торган егет иде» дип искә ала классташлары. Фазыл яхшы билгеләргә генә баян классы буенча музыка мәктәбен тәмамлый, мәктәптә дә ул бик яхшы укып, БДИны югары балларга бирә һәм КФУның икътисад һәм финанс институтына укырга керә. Фазыл хәзер 4нче курс студенты.

Мәктәптә балачакта актив булган Фазыл, студент елларында да үзен бары тик уңай, яхшы яктан гына күрсәтә! КВНда катнаша, җырлый, бии, концертлар куя – студент тормышының үзәгендә кайный! Аны белмәгән кеше, таныш булмаган студент, тавышына, ул уйнаган гитара чыңына гашыйк булмаганнар юктыр...

Бүгенге көндә Фазыл әти-әнисенең бердәнбер дәвамчысы! Ул яшәргә тиеш! Бернигә дә карамастан, дәваланып, алга атларга, яңа хыяллар, уйфикерләр белән киләчәккә барырга тиеш!

Бу дөньяда аны үзенең чиксез яшәү теләге; якыннары, туганнары, дусларының булышлыгы; табибларның ярдәмнәре генә тота. Терелү һәм дәвалану курсларын башлап җибәрер өчен бердәнбер киртә – дәвалану бәясенең коточкыч кыйммәт булуы – 4 млн сум! Фазылның әти-әнисе кыска вакыт эчендә үзләре генә бу кадәр акчаны җыеп бетерә алмый! Мондый авыруларны безнең илдә дәвалау тәҗрибәсе аз, Фазылга Германиядән клиника эзлиләр. Бу бик зур финанслар таләп итә!

20 яшьтә тормыш әле башланырга гына тиеш. Без барыбыз да Фазылның бәхетле, сәламәт тормыш итүенә тагын бер мөмкинлек бирә алабыз! Бары тик теләк кенә кирәк!




Ә син, Фазыл, бернигә дә карамастан, яшәргә тиеш!

***Фазылның дусты Артур Шакиров:***

«Фазыл – киң күңелле, дөньяны үлеп яратучы кешеләрнең берсе. Ул һәрвакыт күтәренке кәеф белән йөри. Башкаларга да беркайчан да моңсуланып утырырга ирек бирми. «Балланс» концертына бергә әзерләнгәндә, аның шат тавышы, көлүе әллә кайларга ишетелә иде. Фазыл бик акыллы, укымышлы егет – әңгәмә вакытында да төрле темага кушылып китә ала, футболмы ул, киномы, театр дөньясымы, әллә яңа китапмы...Минемчә,Фазыл– иң якты талантларның берсе! Андыйлар бу дөньяда бик сирәк…»

***Дима Бегимов:***

«Фазыл белән бер лекцияләргә йөрибез. Бу кеше миндә кызыксыну уята, аңа һәрвакыт хозурланып карый идем. Фазыл– чын шәхес ул! Беркайчан да миллионлаган кеше артыннан китми, һәр ситуациягә үз карашы, үз фикере, үз билгесе бар. Ул «ясалма» кешеләрдән үзенең чын булуы белән, гадилеге белән аерылып тора! Аның авыруы турында ишеткәч, күңелемдә сәер бушлык урнашты. Фазылның диагнозына әле һаман да ышанып бетә алмыйм! Ләкин беләм, бу егет, һичшиксез, аякка басачак. Бүтәнчә була да алмый. Яңадан университет диварлары эчендә аның кулын кысып: «Сәлам, Фазыл!» – дип күрешәсем килә!».

Ярдәм итәргә теләүчеләр өчен реквизитлар:
-Мегафон (+7-927-443-35-17)
-Яндекс.Деньги (410011553049847)
-Qiwi кошелек (9872601054)
Тулырак мәгълүматны vk.com/fazylsos төркемендә белергә була.

● Юбилей

# «Дарелфөнүн»гә бер яшь!



**Рифат СӘЛАХ, «Дарелфөнүн» газетасының мөхәррире:** Казан университетының беренче татар студентлары газетасы – «Тәрәзә» – 2003 елдан бирле чыга башлады. Дөрес, ул даими эш урыны белән тәэмин ителмәгән, бары татар студентларының энтузиазмы; ул вакыттагы татфак студенты, хәзер инде филология фәннәре кандидаты, Ленар Шәехнең башлап йөрүе нәтиҗәсендә чыга бирде. Университетыбызга ТДГПУ, КДФЭИ кебек югары уку йортлары кушылып федеральләшкәч, Рамил әфәнденең тырышлыгы белән, ниһаять, атнага бер чыга торган даими татар басмасы – «Дарелфөнүн» барлыкка килде.

Газетабыз студентлар өчен менә дигән мәйдан. «Дарелфөнүн» битләрендә «Әллүки», «Илһам» әдәби-иҗат берләшмәләренә йөрүче студентларның яңа гына табадан төшкән әсәрләре белән дә танышырга мөмкин. Монда һәр студент та талантын ача, һәр галимебез дә яңадан-яңа ачышлары белән сөендерә ала! Киләчәктә газетабыз студентлар, галимнәребез һәм университет тормышы белән янәшә барыр, иншалла!



**Рамил ХАННАНОВ, 2011-2012 елларда «Дарелфөнүн» газетасының мөхәррире:**
Шушы көннәрдә уку йортыбызның милли татар телендә нәшер ителә торган төп матбугат чарасы оешуга бер ел тула. Әйе, күп вакыт түгел... Тик профессиональ дәрәҗәдә студентлар өчен татар телендә тәүге газета чыга башлаганга быел 6 ел!

Нәни юбилярыбыз – «Дарелфөнүн» үзенең башлангычын нәкъ шуннан ала. Мәгълүм сәбәпләр аркасында 5 яшьлек «Яшьлек тавышы» газетасы атамасы үзенең дәвамчысына куелмаса да, иҗади студентларны берләштергән матбугат чарабызның үсеп, тернәкләнеп китүенә җирлек бар иде! Куәтле яшь хәбәрчеләр сафы артканнан-арта барды, яңадан-яңа сәхифәләр ачылды, газета федераль югары уку йорты мәйданына чыкты.

Алга таба яңа мөхәррир һәм сәләтле иҗат төркеменнән торган коллективка зур уңышлар телим! Редакциягә язмалар күп килсен, архив ташып торсын, яңадан-яңа идеяләр укучыларны үзенә җәлеп итсен. Сайлаган йөзебезне югалтмыйча, хаталардан азат булып, туган уку йортыбыз – дарелфөнүнебез үсешендә милли елъязмачы булуын онытмыйча үсик!

**Гөлфия КАМАЛИЕВА,** Газетабыз «Яшьлек тавышы» җирлегендә барлыкка килсә дә, ул яңа университет газетасы. Шуңа күрә, аның эчтәлеге генә түгел, бизәлеше дә яңа булырга тиеш. Бу өлкәдә эшләү минем өчен шактый кызыклы. Дөрес, беренче генә газетам түгел, ләкин аларның һәрберсе дә күңелдә тирән эз калдыра, туганың кебек якын була. Һәр рәссам яңа картина язган кебек, яңа газета макетын булдыру минем өчен яңа бер иҗади уңыш иде. Дизайнда да һәр төснең эчтәлеге бар. «Дарелфөнүн»ебездә өстенлек алган зәңгәр төс – белемгә омтылу, фән төсе ул. Газетабызның гомере озын булып, укучыларыбызны үзенә җәлеп итеп торсын!



**Динара ӘХМӘТОВА:**
«Дарелфөнүн» – тормышымның бер өлеше ул. Газетабызның тәүге номерын әзерләгән вакытлар бүгенгедәй күз алдымда. Исемен дә бик тиз уйлап таптык. Уку йорты тормышын яктырта торган газетага тагын нинди исем куеп була инде? Ул биш ел дәвамында ТДГПУда чыгып килгән «Яшьлек тавышы» газетасы нигезендә барлыкка килде. Яңа сулыш, кызыклы сәхифәләр, тагын да мавыктыргыч язмалары белән «Дарелфөнүн» буларак укучыларның күңелен яулый башлады. Камиллекнең чиге юк: газетабыз үзгәрә, үсүен дәвам итә. Аның белән бергә без дә тәҗрибә туплыйбыз, тагын да югарырак үрләргә омтылабыз. Газетабызга озын гомер, ә хезмәттәшләремә иҗади уңышлар телим!



**Сиринә ТРОФИМОВА:**
Газетабызның беренче номеры чыккан вакытта Казан федераль университеты эшли башлаганга да ярты ел гына, редакциядә без өчәү генә идек әле. Тегендә-монда күчеп йөри торгач, безне Болак буендагы (хәзерге Физкультура институты) бинаның икенче катының тар гына бер бүлмәсенә урнаштырдылар. Минем өчен яңа эш урыныбызга килеп керү мизгеле дулкынландыргыч та, шатлыклы да булды. Моннан 36 ел элек, бу бинада яңа гына мәктәпне тәмамлаган, киләчәккә зур хыяллар белән килгән абитуриент – Сиринә Мөрсәлимова татар әдәбиятыннан, татар теленнән Казан дәүләт педагогия институтына укырга керү өчен имтиханнар тапшырып йөргән идем... Менә шулай, дусларым, бер яшьлектә, бер картлыкта дигән кебек булды бу.



«Дарелфөнүн» газетасының беренче саны дөнья күрер алдыннан күңелем белән кабат-кабат яшьлегемә, студент елларыма кайтып килдем. Ул чакта факультетның «Яшь көч» дип аталган стена газетасында актив хәбәрче идем. Хәзерге көнгә кадәр мәктәп укучылары, республикабыз һәм башка төбәкләрдәге татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән эш тәҗрибәмнең зур булуы, замана яшьләренең проблемаларын өйрәнеп, күзлектән килгәнлектән, «Дарелфөнүн» газетасында эшләгән бер елымны – тормыш бүләге дип кабул итәм. Бик яратып эшләдем мин анда. Газетабызның киләчәктә дә студентларның, укучыларның якын дусты, киңәшчесе булуын телим!

**Зилә ФӘСХИЕВА:**
«Дарелфөнүн» газетасында эшли башлавым өчен Рамил Ханнановка рәхмәтлемен. Ул тәкъдим итмәгән булса, гомумән хәзер бу коллективта утырыр идемме икән?!

Ә эш дәверендә мин бик күпкә өйрәндем: вакытны дөрес итеп бүләргә, һәрбер нәрсәгә оптимистик күзлектән карарга, җаваплы булырга... Әлегә студент булуыма карамастан, эш белән укуны бергә бәйләп бару – минем өчен көн тәртибендәге бер



кагыйдә кебек. Берсе-берсенә киртә куймый, ә киресенчә үсәргә ярдәм итә... Бер ел шулай үтеп тә киткән... Күпме кешеләр белән аралашылган, үзем өчен күпме мәгълүмат тупланган. Барыннан да бигрәк коллективыбызның дус-тату булуы ошый. Эштән укуга һәрчак яхшы кәеф, күңел күтәренкелеге белән китәм. Алга таба да нинди генә коллектив булуына карамастан, газета яшәүдән туктамасын, укучылары артып торсын иде!

**Алинә САДЫЙКОВА:**
Ышанып та булмый: монда эшли башлавыма дүрт айдан да артып киткән икән... Кулга диплом да алмаган килеш беренче тапкыр редакциягә курка-курка килүем әле кичә генә булган шикелле... Анда да юл сораганнан соң, мине бинаның иң аскы катына, подвалга төшереп җибәргәннәр иде. Беренче фикерем: «Абау, шушы подвалда эшлисе булырмы



икән?» Юк, бәхетемә, алар өченче катта булган. Коллектив бик җылы кабул итте, аларның дуслык мөнәсәбәте бу эшемдә беренче адымнарымны ясарга бик нык ярдәм итте. Мондый өлкәдә эшләп китәрмен дип һич тә уйламый идем, ә язмыш җилләре менә кая китереп ташлады. Остазым Гөлфия Расиловнага бик зур рәхмәт – ул вакытында язу сәләтемне күреп алып, көчемне сынап карарга киңәш итте. Берничә ай эшләү дәверендә газетаның күпме үзгәреш кичерүен төгәл генә әйтә алмыйм, әмма шушы вакыт эчендә «Дарелфөнүн» мине күп әйберләргә өйрәткәнен, аның мине үзгәрткәнен тәгаен раслый алам. Әле бу озын юлның башы гына, яулыйсы үрләр алда! Газетаны исә иң зур һәм иң кечкенә юбилее белән тәбрик итәм, аңа озын гомер һәм гел яңа укучылар табып торуын телим!

**Динара ЗИННӘТОВА:**
Журфакта укыгач, җәйләрен практика узу өчен уңайлы да, үзең өчен файдалы һәм кызыклы да булган редакция табарга тырышасың. Һәрберебезнең виртуаль тормышына әйләнгән бер социаль челтәрдә игълан язарга булдым – яшь журналист язмалары өчен берәр мәйдан табылмас микән? Озак көтәргә туры килмәде – адашым Динара Әхмәтова шул ук көнне диярлек мине университетта татар телендә чыга торган газета редакциясенә чакырды.

Студент тормышының кызыклы яклары турындагы язмаларым «Дарелфөнүн»дәгеләрнең күңеленә хуш килде. Җәйге практиканы бу юлы, үткән еллардан аермалы буларак, уңышлы башкардым: үземә дә бик якын булган темалар – студент проблемалары, төрле кызыклы вакыйгалар турында язмалар әзерләү җиңел һәм рәхәт иде. Күтәренке кәеф, яшьлек атмосферасында эшләп килгән редакциягә бик теләп эшкә урнаштым мин. Хәзерге вакытта коллектив белән танышуыма һәм шундый кызыклы эш урыны табуыма чиксез шатмын.



реклама




DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ЖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.